| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**03.08.2021** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1832** |

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы мәгариф учреждениеләренең түләүле хезмәтләр күрсәтүгә хезмәт күрсәтүләр һәм тарифлар исемлеген раслау турында» 2010 елның 18 мартындагы 504 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 17 февралендәге 255 номерлы карарындагы кушымтасына өстәмәләр кертү турында (2016 елның 22 декабрендәге 3690 номерлы үзгәрешләрне исәпкә алып)

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 4 пункты нигезендә һәм 2021 елның 23 июленнән Зеленодольск муниципаль районының муниципаль предприятиеләре һәм учреждениеләре хезмәтләренә тарифларны (бәяләрне) карау комиссиясе карары буенча Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы мәгариф учреждениеләренең түләүле хезмәтләр күрсәтүгә хезмәт күрсәтүләр һәм тарифлар исемлеген раслау турында» 2010 елның 18 мартындагы 504 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 17 февралендәге 255 номерлы карарындагы 28 нче кушымтасына, кушымтага туры китереп, пункт өстәргә.
2. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигына әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (www.zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - мәгариф идарәсе башлыгына йөкләргә.

Җитәкче в.б. А.В. Старостин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
кушымта
03.08.2021 №1832

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы**
**Осиново ав. «В.В. Карпов ис. лицей»**
**муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе**

**Түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтүгә**
**хезмәт күрсәтүләр һәм тарифлар исемлеге**

| Түләүле хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү берәмлеге өчен тариф (сәг.) сум. |
|---|---|
| Физкультура-сәламәтләндерү чараларын уздыру өчен спорт залы бирү | 800 |